ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 март 2026 ел № 2446

Башкарма комитетның 2023 елның 26 маендагы 4328 номерлы Карары белән расланган шәһәр бюджеты акчаларын казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 26 маендагы 4328 номерлы Карары белән расланган шәһәр бюджеты акчаларын казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның дүртенче абзацында «(аларның бүлендек җәмгыятьләренең)» сүзләреннән соң «грантлар» сүзләрен өстәргә;

2) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Казначылык аша үткәргәндә Федераль казначылыкның территориаль бүлекчәсе, бюджет акчаларын алучы һәм казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучы арасында документлар алмашу электрон имза кулланып гамәлгә ашырыла. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны яисә дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар булмаган карау мөмкинлеге чикле мәгълүматны үз эченә алган муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) буенча казначылык аша үткәрүдә катнашучы тарафыннан Федераль казначылыкның территориаль органына санкцияләү тәртибендә билгеләнгән формалар буенча мондый муниципаль контракттан, шартнамәдән (килешүдән), контракттан (шартнамәдән) өземтә, шулай ук казначылык аша үткәрүдә катнашучының

акчалата йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документтан өземтә (алга таба тиешенчә - документ-нигез, документ-нигездән өземтә) бирелә.

Әлеге тәртиптә каралган дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшыру һәм саклау Россия Федерациясенең дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне саклау турында законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контракттан, шартнамәдән (килешүдән), контракттан (шартнамәдән) өземтәдә, документ-нигездән өземтәдә күрсәтелгән мәгълүматның дөреслеге һәм муниципаль контракт, шартнамә (килешү), контракт (шартнамә), документ-нигез шартларына туры килүе өчен муниципаль заказчы, бюджет акчаларын алучы, контракт (шартнамә) буенча заказчы җаваплы.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов